УДК 811.512.145

***Р.Ф. Мирхәев***

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ПРОЗАСЫ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ СЫЙФАТ ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ СТИЛИСТИК КУЛЛАНЫЛЫШЫ

Конец XIX – начало XX веков в истории татарского литературного языка характеризуется как период его наивысшего развития в функциональном и структурном планах. Функционировавший до этого в основном в поэтических произведениях и религиозно-дидактических трактатах старотатарский язык начинает проникать в новые для него общественные сферы, художественные, публицистические и научные жанры. Статья посвящена изучению особенностей стилистического употребления в произведениях татарской просветительской прозы конца XIX – начала XX веков причастий, которые, будучи одним из основных элементов грамматической структуры языка, играют важную роль в формировании языковой ткани письменных текстов. До настоящего времени в работах татарских ученых по истории татарского литературного языка они описывались лишь фрагментарно. При этом их стилистический потенциал оставался вне поля зрения языковедов.

**Ключевые слова:** старотатарский язык, язык татарской просветительской прозы, неличные формы глагола, причастные формы, стилистическое употребление.

The end of the 19th – beginning of the 20th centuries in the history of the Tatar literary language is characterized as the period of its highest development in functional and structural terms. The Old Tatar language, which previously functioned mainly in poetry and religious and didactic treatises, was getting into new social spheres, artistic, journalistic and scientific genres. The article is devoted to the study of the peculiarities of the stylistic use of participles in the works of Tatar educational prose of the late XIX – early XX centuries, which being one of the main elements of the grammatical structure of the language play an important role in the formation of the language of written texts. Until now, in the works of Tatar scientists on the history of the Tatar literary language, they were described only partially. At the same time their stylistic potential remained outside the view of linguists.

**Keywords:** Old Tatar language, the language of Tatar educational prose, impersonal forms of the verb, participial forms, stylistic use.

Гасырлар дәвамында иске татар әдәби теленең табигатен, аның үсеш закончалыкларын билгеләгән язма традицияләр, норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык [Бәширова, 2008, б. 6; Татар әдәби теле тарихы, 2017, б. 706–827] сыйфат фигыль формаларының кулланылышында да күзәтелә. Язма чыганаклардан күренгәнчә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби телендә аларның парадигматик һәм синтагматик мәгънәләре кыпчак һәм угыз телләренә хас булган әдәби норма күрсәткечләре

белән белдерелә. Әлеге мәкалә кысаларында XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләре телендә сыйфат фигыльләрнең, аерым алганда бүгенге көндә дә әдәби телдә норма күрсәткечләре буларак яшәвен дәвам иткән *-учы, -а торган, -р, -ачак* һәм *-ган* кушымчалы формаларның стилистик кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү максат итеп куелды.

*-учы* кушымчалы сыйфат фигыльләр хәзерге татар әдәби телендә башлыча атрибутив позициядә, ягъни сыйфат фигыльнең үз мәгънәсендә генә кулланылып, субъект, ә төшем юнәлешендә кулланылган очракта объект мәгънәсен белдергән сүзләрне ачыклап киләләр. Күпчелек очракта алар субъект яисә объектның гомуми билгесенә әверелгән һәм билгеле бер заманга карамаган процессны белдерә. Шул ук вакытта җөмләдәге төп фигыльгә мөнәсәбәттә аның белән бер үк вакытта һәм аннан алда башкарылган эш-хәрәкәтне дә белдереп килә алалар [Татар грамматикасы, 2016, б. 241–242].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-учы* кушымчалы сыйфат фигыльләр мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда һәм газета текстларында очрыйлар [Шамарова, 1990, с. 77; Миннуллин, 2012, с. 190–191]. Аерым кулланылыш очраклары дини-фәлсәфи хезмәтләрдә теркәлгән [Абдулхаков, 2007, с. 21]. Ләкин шигъри әсәрләр теле өчен алар хас түгел, ягъни *-учы* кушымчалы сыйфат фигыльләр бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алмыйлар һәм функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар.

*-учы* кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыльләр XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтче язучыларыннан күбесенчә Р. Фәхретдин әсәрләрендә очрыйлар. Язучы аларны, нигездә, автор сөйләмендә, публицистик чигенешләрдә куллана, ягъни билгеле бер иҗтимагый максатларга буйсындырып файдалана: *Тәрбийәле қызлар хатын улдықлары соңында бер өйне ғақыл илә идарә қылырлар, баланы гүзәл тәрбийә идәрләр, ирләренә ышанычлы вә туғры ғақыл вә киңәш* ***вирүче****, күңелләрене* ***шатландыручы****, серләрене һәм мөхкәм* ***сақлаучы*** *ибдәш улырлар* [Фәхретдин, 1899, б. 68].

*-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләр хәзерге татар әдәби телендә күбрәк атрибутив позициядә кулланылалар һәм эш-хәрәкәтнең субъектын, объектын, башкарылу урынын, вакытын белдергән һәм корал мәгънәсендәге сүзләрне ачыклап киләләр. Алар, нигездә, субъект яисә объектның гомуми билгесенә әверелгән процессны белдерәләр. Чагыштырмача сирәк очракларда *-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләр үзләре ачыклап килгән сүзләрне сөйләү моменты белән бер вакыт яссылыгында башкарылган, ягъни хәзерге заманга караган эш-хәрәкәт буенча характерлыйлар [Татар грамматикасы, 2016, б. 244–245].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләр мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка

ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда һәм газета текстларында очрыйлар [Шамарова, 1990, с. 77; Миннуллин, 2012, с. 190–191]. Башка язма чыганаклар өчен алар хас түгел. *-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләр бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алмыйлар һәм функциональ-стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып торалар. Бу аларның әдәби кулланылышка яңа керә башлавы һәм мәгънәләренең язма текстларда башка затланышсыз фигыльләр тарафыннан белдерелүе белән аңлатыла.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләр М. Акъегет һәм З. Бигиев романнарында гына очрыйлар. Бирелә дә алар сирәк кулланылалар. Язучылар бу затланышсыз фигыльләргә, нигездә, персонажларның портретларын биргәндә һәм теге яки бу объектны тасвирлаганда мөрәҗәгать итәләр: *Сәлимгәрәй хәзрәтләренең йөзе адәмне* ***бақтыра торған, тарта торған*** *вә* ***әмнийәт чықарта торған*** *қыйафәт иде* [Акъегет, 1886, б. 43]; *Муса әфәнде йалғыз бер бүлмәйә мәхбүс улыб, бу бүлмәсе дә ат уғрысыны* ***хәбес қыла торған*** *бүлмә кеби кечек қараңғы вә пычрақ вә суық улмайынча, бер бүйүк бүлмә иде* [Бигиев, 1887, б. 34].

*-р* кушымчалы сыйфат фигыльләр хәзерге татар әдәби телендә төрле мәгънәдәге (субъект, объект, урын, вакыт) сүзләр белән кулланылалар һәм аларны нинди дә булса заманга мөнәсәбәтсез даими башкарыла торган яисә киләчәктә булачак эш-хәрәкәт буенча ачыклап киләләр [Татар грамматикасы, 2016, б. 229–230].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-р* кушымчалы сыйфат фигыльләр мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда, шигъри әсәрләрдә, газета текстларында һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә кулланылалар [Шамарова, 1990, с. 78; Юсупов, 2006, с. 115; Миннуллин, 2012, с. 198–199; Абдулхаков, 2007, с. 21]. Алар бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норманың бер күрсәткече булып торалар.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә *-р* кушымчалы сыйфат фигыльләр, нигездә, автор сөйләмендә, пейзаж тасвирламаларында һәм публицистик чигенешләрдә кулланылалар. Аерым очракларда язучылар әлеге сыйфат фигыльләрне персонажлар сөйләменә дә кертеп җибәрәләр: *Безем милләтемез кеби* ***утанмаз, ойалмаз*** *бер милләт, ғоман идәрем, һичбер йирдә йуқдыр* [Бигиев, 1908, б. 33]; *«Тәрҗеман» исә бу бабда дөнйа* ***тәхмил итмәз*** *дәрәҗәдә мөшкелләрне йөкләб мәсләгендә сабит улмышдыр* [Фәхретдин, 1899, б. 76].

Моннан тыш әлеге сыйфат фигыльләр, персонажга хас булган нинди дә булса сыйфатның дәрәҗәсен күрсәткәндә яисә башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен тасвирлаганда, чагыштырулар составында кулланылалар: *Чөнки* ***сүзләшер*** *қадәр русчаны бән белмидер*

*идем* [Фәхретдин, 1899, б. 19]; *Бунлар гүйә қаты қычқырышмақ* ***мөсабәқасы (йарышмақ) идәр*** *кеби бер-берендән артық қычқырышырлар* [Фәхретдин, 1903, б. 59].

*-ачак* кушымчалы сыйфат фигыльләр хәзерге татар әдәби телендә атрибутив позициядә төрле мәгънәдәге (субъект, объект, урын, вакыт) сүзләр белән кулланылалар һәм аларны киләчәктә башкарылачак эш-хәрәкәт буенча ачыклап киләләр. Билгеле бер контекстта алар сыйфатланмышларыннан башка һәм исем фигыль буларак та кулланыла алалар [Татар грамматикасы, 2016, б. 238–240].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-ачак* кушымчалы сыйфат фигыльләр мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән башка ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда, шигъри әсәрләрдә, газета текстларында һәм дини-фәлсәфи хезмәтләрдә кулланылалар [Шамарова, 1990, с. 78; Юсупов, 2006, с. 114–115; Миннуллин, 2012, с. 198; Абдулхаков, 2007, с. 21]. Алар бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норманың бер күрсәткече булып торалар.

М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында *-ачак* кушымчалы сыйфат фигыльләр күбрәк исем фигыль функциясендә теркәлде: *Чүнкә менла иртәгә сабахда шәһәрә* ***киләчәгене*** *тәхсис әйләмеш иде* [Акъегет, 1886, б. 36]; *Икенче көн Ғаббас аға баш қодаларның тәклифене рәд итмәйеб диде ки, икенче* ***киләчәгеңездә*** *сүзне тәмамлармыз вә шу хәлдә баш қодаларны озатты* [Акъегет, 1886, б. 36].

З. Бигиев *-ачак* кушымчалы сыйфат фигыльләрне, нигездә, атрибутив позициядә файдалана һәм аларга укучының игътибарын теге яисә бу предмет һәм затка хас булган сыйфатка юнәлткәндә мөрәҗәгать итә, ягъни билгеле бер сәнгатьчә стилистик максатларга буйсындырып куллана: *... секретарьнең өстәленә* ***хөкем wақытында зарур улачақ*** *кәғазьләрне ба тәртиб қуйадыр иде* [Бигиев, 1887, б. 38]; *Шәһәрләрдә* ***ахун вә хатиб җәһәтләренә керәчәк*** *адәм русча йазмақ вә уқымақ, хисаб қылмақ белмәсе лязимдер* [Бигиев, 1890, б. 13].

Аерым очракларда автор *-ачак* кушымчалы сыйфат фигыльләрне персонажларның хис-кичерешләренә бәйле рәвештә аларның дәрәҗәсен тасвирлаганда, башка эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен күрсәткәндә чагыштырулар составында файдалана: *Хәдичә туташ да бу кеби гүзәл мәслихәтне ишедеб,* ***тәхте қаләмдә тәмам улмайачақ қадәр*** *шадланды* [Бигиев, 1887, б. 29]; *Романымызда мәхлуқ улан әшхасның әксәре гөнаһлы бәндәләр улыб, дөнйалары башдан ахырына қадәр хараб вә бишекдән қаберә қадәр фәләк ғаддарында булындықлары бу wақыйғадан* ***мәғлүм улачағы кеби*** *йәүме мәхшәрдә ғафурер рәхим аллаһының рәхмәте вә фазылына мөлақат қылмасалар, әһле җәһәннәм улдықлары аңлашылачақдыр* [Бигиев, 1890, б. 2].

Р. Фәхретдин романнарында *-ачак* кушымчалы сыйфат фигыльләрнең кулланылыш даирәсе башка чыганаклар белән чагыштырганда күпкә киңрәк. Биредә алар күбесенчә атрибутив позициядә һәм исем фигыль урынында киләләр. Атрибутив позициядә язучы бу

сыйфат фигыльләрне, нигездә, иҗтимагый мәгънә төсмерләре белән баетып, предмет яки затның киләчәктә башкарылачак эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль билгесе турында сүз алып барганда куллана: *Җәмгыйәтемезне алга йибәрергә* ***сәбәб улачак*** *гыйлем wә мәгрифәт әһелләрене йитешдермәк сезгә лязимдер* [Фәхретдин, 1899, б. 10]; *Бәлки қалдырмыш улыр идем, бу тугрыда* ***йул күстәрәчәк*** *галимләр вә гақыллы адәмләре кәндемдән биздердем* [Фәхретдин, 1903, б. 106].

Моннан тыш автор *-ачак* кушымчалы сыйфат фигыльләрне башка эш-хәрәкәтнең, яисә персонажга хас сыйфат-билгеләрнең дәрәҗәсен күрсәткән конструкцияләрдә дә файдалана: ... ***афәрин уқытдырачақ дәрәҗәдә*** *гарәбчәне дөрест сүзләшә белдекләрене; ...газеталарда уқыр идем* [Фәхретдин, 1899, б. 20]; *Қаваи ноқтасы вә хитабларында улан фәсахәт вә бәлагате гақыллары* ***хәйран идәчәк дәрәҗәдә*** *улмышдыр* [Фәхретдин, 1903, б. 6].

*-ган* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләр хәзерге татар әдәби телендә атрибутив позициядә төрле мәгънәдәге (субъект, объект, урын, вакыт) сүзләр белән кулланылалар һәм аларны, нигездә, үткәндә башкарылган эш-хәрәкәт буенча ачыклап киләләр, ләкин бу сыйфат фигыльләрнең заман мәгънәсе җөмләдәге төп эш-хәрәкәтнең заманы белән билгеләнә. Билгеле бер контекстта *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләр сыйфатланмышларыннан башка, ягъни исемләшкән хәлдә һәм исем фигыль буларак та кулланыла алалар [Татар грамматикасы, 2016, б. 213–224].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләр, мәгърифәтчелек прозасы әсәрләреннән тыш, ярым тезмә, ярым чәчмә характерда иҗат ителгән дастаннарда, шигъри әсәрләрдә һәм газета текстларында кулланылалар [Шамарова, 1990, с. 78; Юсупов, 2006, с. 109–110; Миннуллин, 2012, с. 194–195]. Алар дини-фәлсәфи хезмәтләрдән кала бу чорда иске татар язма әдәби теле чагылыш тапкан барлык язма чыганакларда да урын алалар һәм әдәби норма, норма вариантлылыгының бер күрсәткече булып торалар.

Мәгърифәтче язучылар *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләрне автор сөйләмендә куллану белән бергә персонажлар сөйләменә дә кертеп җибәрәләр: ... *– Икмәкләремне пичкә* ***қуйганда*** *көрәгем йарылды, көрәк сорарга барамын балақай! – җавабланды қарт қадын...* [Акъегет, 1886, б. 51]; ... *– Әгәр дә шушы мәңа* ***сөйләгән*** *сүзләрне следователь хозурында сөйләсәң, инша аллаһ, Маһруйга файдасы улыр иде һәм сәне дә разый қылыр идем ...* [Бигиев, 1890, б. 44–45].

Алга таба әлеге сыйфат фигыльләр аерым күренешләрнең тасвирламаларында очрый: *Атны сарай астында* ***йирләшдергән*** *заманда менланың күзенә гүзәл бер күренеш раст килде* [Акъегет, 1886, б. 9]; *Шимди исә, ахунд хәзрәтләренә тәгзыймән* ***ултырышқан*** *кешеләр торыб ултырган wақытда, урынсызлар да тыгызланыб-нидеб, җәмәгать арасына ултырышдылар* [Бигиев, 1887, б. 38].

Шуның белән бергә язучылар аларны күбрәк предмет яисә затның үткәндә башкарылган эш-хәрәкәт белән бәйле процессуаль

билгесе турында сүз алып барганда кулланалар: *Бу эшдә шаһид дәгел сез, бәлки **тәфтишдә табылган** нәрсәләр сезнең ҡатыйле Зөләйха улуыңыза дәләләт ҡылалар* [Бигиев, 1887, б. 20–21]. *Господин Андреевның ... мөшавәрәсендән соңра өч-дүрт көн кичкәч, сабах сәгать 11дә мәқтүлә Зөләйханың номерене **тәфтиш ҡылган** судебный следователь кәнде ивендә ... господин Шубин илә кофе эчийүрлар* [Бигиев, 1887, б. 30]; *Болгарлылар **галиб улган** татарлар илә ҡатышыб, татарлар һәм үзләре бетдекләре хәлдә, исемләрен ҡалдырмышлардыр* [Фәхретдин, 1899, б. 29]; *Дәрестә **ишеткән** файдалы нәрсәләреме сөйләргә көчем йитмәз* [Фәхретдин, 1903, б. 84].

*-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләргә З. Бигиев башка эшхәрәкәтнең башкарылу рәвешен тасвирлаганда да мөрәҗәгать итә. Бу очракта ике процесска нигезләнгән чагыштырулар барлыкка килә: *Муса әфәндейе мәхкәмәдән үле кешейе **чыҡарган кеби** күтәреб чыҡардылар* [Бигиев, 1887, б. 47]; *Җиһангир хезмәтчедән бу сүзләре ишеткәч, өстендән бер агыр таш **төшкән кеби** улыб, хәле йиңел улды* [Бигиев, 1890, б. 45].

Р. Фәхретдин алар ярдәмендә градацияләр тудыра: *Ҡазанда улган мәдрәсәдә ун сәнә гомер уздырыб, **уҡыган** дәресләрем күб, **белгән** нәрсәләрем чиксез, **күтәргән** китабларым хисабсыз иде* [Фәхретдин, 1899, б. 6].

Моннан тыш ул *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльләрне пейзаж картиналарында һәм публицистик чигенешләрдә теге яки бу объект яисә затка гомумән хас булган билгене тасвирлаганда куллана: *... күккә аз гына **йитмәгән** таулар күңелгә ләззәт китерә иде* [Фәхретдин, 1899, б. 22]. ***Гыйлем вә мәгрифәте улмаган** бер ана үз баласыны тийеш сурәтдә тәрбийә идә алмаз* [Фәхретдин, 1899, б. 66].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчелек прозасы әсәрләрендә без тикшергән сыйфат фигыль формаларының барысы да стилистик планда сәнгатьчә образлылык тудыру яисә билгеле бер иҗтимагый фикерне җиткерү максатларына буйсындырылып файдаланыла. Ягъни әдәби әсәрләр иҗат ителгәндә, публицистик хезмәтләр язылганда, укучыга эстетик тәэсир итү һәм этик йогынты ясау өчен, язучылар, шагыйрьләр тарафыннан тел системасының барлык берәмлекләре дә эшкә җигелә.

**Әдәбият**

*Акъегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Абдулхаков Р.Р.* Языковые особенности произведений Мусы Джаруллаха Бигиева: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 24 с.

*Бәширова И.Б.* XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби теле: жанр-стильләре, аерым грамматик категорияләрдә норма һәм вариантлылык. Казан: ТӘһСИ, 2008. 340 б.

*Бигиев З.* Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә. Роман. Казан: Типогр. Г.М. Вечеслава, 1887. 77 б.

*Бигиев З.* Гөнаһе кәбаир. Роман. Казан: типогр. Г.М. Вечеслава, 1890. 72 б.

*Бигиев З.* Мавәраэннәһердә сәяхәт (Транс-Оксанияйә сәфәр). Казан: Типолитогр. И.В. Ермолаевой, 1908. 108 б.

*Миннулин Б.К.* Татарская газета «Борхане таракки». Лингвистические исследования. Казань, 2012. 300 с.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадыйрова, Р.Ф. Мирхәев; фәнни ред. Ф.М. Хисамова. Казан: ТӘһСИ, 2017. II т.: Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. 888 б.

Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 432 б.

*Фәхретдинев Р.* Сәлимә яки гыйффәт. Гафил бән Габдулла әсәре уларак бер хикәятдер. Казан: Типогр. Б.Л. Домбровского, 1899. 80 б.

*Фәхретдинев Р.* Әсма яки гамәл вә җәза. Оренбург: Типогр. М.-Ф. Г. Каримова, 1903. 130 б.

*Шамарова Г.Б.* Язык дастанов А. Уразаева-Курмаши «Кисса-и буз джигит», «Кисса-и Тахир и Зухра»: дис. … канд. филол. наук. Казань, 1991. 166 с.

*Юсупов А.Ф.* Язык произведений Шамсетдина Заки. Морфология. Казань: Казанский государственный университет им. В.И. Ульянова-Ленина, 2006. 204 с.

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*